КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 27

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

5 бүлекнең 5.3 нче пунктындагы утыз икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Психиатрия ярдәме күрсәтүче, кеше иммунитеты җиткелексезлеге вирусы белән авыручыларны диагностикалауны һәм дәвалауны гамәлгә ашыручы медицина хезмәткәрләренә һәм эше кеше иммунитеты җиткелексезлеге вирусы була торган материалларны кулланып эшләүгә белән бәйле булган, шулай ук туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнаша торган затларга зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эштә эшләгән өчен компенсация түләүләре күләмнәре бу Нигезләмәгә теркәлгән 12 нче кушымтада бирелгән күләмнәрдә билгеләнә. Башка хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүнең яңа системасын гамәлгә кертү вакытына әлеге түләү, аны элегрәк алган очракта, хезмәт шартларына махсус бәя бирү үткәргәндә кадәр билгеләнә. Шул ук вакытта эш бирүче хезмәт шартларына махсус бәя бирү үткәрү чарасын күрә. Әгәр дә хезмәт шартларына махсус бәя бирү үткәрү йомгаклары буенча эш урыны куркынычсыз дип танылса, әлеге түләүне башкару гамәлгә ашырылмый. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүнең минималь күләме хезмәт шартларына махсус бәя бирү нигезендә вазыйфаи эш хакының 4 проценты күләмендә билгеләнә.»;

6 нчы бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

### «6. Дәүләт оешмасы җитәкчесенең, аның урынбасарларының (шул исәптән директорының), дәүләт оешмасы баш бухгалтерының һәм баш шәфкать туташының (баш акушерының, баш фельдшерының) эш хакын билгеләү тәртибе

6.1. Дәүләт оешмасы җитәкчесенең, аның урынбасарларының (шул исәптән директорының), дәүләт оешмасы баш бухгалтерының һәм баш шәфкать туташының (баш акушерының, баш фельдшерының) эш хакы вазыйфаи эш хакыннан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

6.2.Дәүләт оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи эш хакы, дәүләт оешмасы төренә һәм хезмәт өчен түләү төркеменә карап, дәүләт оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт оешмасы җитәкчесенең хезмәт өчен түләү төркеме төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саныннан, тәүлек буе стационар ярдәм күрсәтүче, Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы дәүләт оешмалары өчен медицина ярдәме күрсәтү дәрәҗәсеннән, психиатрия, наркология һәм туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүче дәүләт оешмаларында койкалар саныннан чыгып билгеләнә.

Дәүләт оешмасының төп персоналына оешманың төзелүенә аларны тормышка ашыру сәбәп булган төп функцияләрнең үтәлүен турыдан-туры тәэмин итүче хезмәткәрләр керә. Дәүләт оешмасының төп персоналына карый торган

хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештерелеп, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Хезмәт өчен түләү төркемен билгеләү өчен төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны ел саен агымдагы елның 1 гыйнвары хәленә карата яки учреждениене оештыру датасына, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә дәүләт оешмасының әлеге күрсәткечен үзгәртү датасына карата дәүләт оешмасы хезмәткәрләрен тарификацияләү нигезендә билгеләнә.

Хезмәт өчен түләү төркемен билгеләү өчен психиатрия, наркология һәм туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүче дәүләт оешмаларында койкалар саны ел саен агымдагы елның 1 гыйнвары хәленә карата яки учреждениене оештыру датасына, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә дәүләт оешмасының әлеге күрсәткечен үзгәртү датасына карата билгеләнә.

6.3. Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре, түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып, дәүләт оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан билгеләнә:

6.3.1. Тәүлек буе стационар ярдәм күрсәтүче, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмалары (тире-венерология диспансерларыннан тыш):

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Медицина ярдәме күрсәтү дәрәҗәсе* | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|---|
| 1 | III | 1000 нән артык |
| 2 | III | 600 дән 1000 гә кадәр |
| 3 | III | 300 дән 600 гә кадәр |
| 4 | III | 300 гә кадәр |
| 1 | II | 180 нән артык |
| 2 | II | 100 дән 180 гә кадәр |
| 3 | II | 100 гә кадәр |
| 1 | I | 58 дән артык |
| 2 | I | 50 дән 58 гә кадәр |
| 3 | I | 45 тән 50 гә кадәр |
| 4 | I | 30 дан 45 кә кадәр |
| 5 | I | 15 тән 30 га кадәр |
| 6 | I | 15 кә кадәр |

* Тәүлек буе стационар ярдәм күрсәтүче, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы дәүләт оешмалары өчен медицина ярдәме күрсәтү дәрәҗәсе Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

6.3.2. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы амбулатор-поликлиника медицина оешмалары:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 110 нан артык |
| 2 | 100 дән 110 га кадәр |
| 3 | 90 нан 100 гә кадәр |
| 4 | 70 тән 90 га кадәр |
| 5 | 30 дан 70 кә кадәр |
| 6 | 30 га кадәр |

6.3.3. Ашыгыч медицина ярдәме станцияләре:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 200 дән артык |
| 2 | 25 тән 200 гә кадәр |
| 3 | 25 кә кадәр |

6.3.4. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, әлеге үзәкнең филиаллары:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Дәүләт оешмалары исеме |
|---|---|
| 1 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |
| 2 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиаллары |

6.3.5. Медицина мәгълүмати-аналитика үзәкләре:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 120 дән артык |
| 2 | 80 нән 120 гә кадәр |
| 3 | 40 тан 80 гә кадәр |
| 4 | 40 ка кадәр |

6.3.6. Медицина профилактикасы үзәкләре:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 65 тән артык |
| 2 | 40 тан 65 кә кадәр |
| 3 | 15 тән 40 ка кадәр |
| 4 | 15 кә кадәр |

6.3.7. Табиб-физкультура диспансерлары:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 60 тан артык |
| 2 | 30 дан 60 ка кадәр |
| 3 | 30 га кадәр |

6.3.8. Наркология диспансерлары:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Койкалар саны |
|---|---|
| 1 | 350 дән артык |
| 2 | 250 дән 350 гә кадәр |
| 3 | 150 дән 250 гә кадәр |
| 4 | 95 тән 150 гә кадәр |
| 5 | 70 тән 95 кә кадәр |
| 6 | 70 кә кадәр |

6.3.9. Психиатрия диспансерлары (хастаханәләре, шифаханәләре):

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Койкалар саны |
|---|---|
| 1 | 1500 дән артык |
| 2 | 1000 нән 1500 гә кадәр |
| 3 | 500 дән 1000 гә кадәр |
| 4 | 200 дән 500 гә кадәр |
| 5 | 150 дән 200 гә кадәр |
| 6 | 110 нан 150 гә кадәр |
| 7 | 50 дән 110 га кадәр |
| 8 | 50 гә кадәр |

6.3.10. Туберкулезга каршы диспансерлар (хастаханәләр, шифаханәләр):

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Койкалар саны |
|---|---|
| 1 | 240 тан артык |
| 2 | 200 дән 240 ка кадәр |
| 3 | 150 дән 200 гә кадәр |
| 4 | 60 тан 150 гә кадәр |
| 5 | 60 ка кадәр |

6.3.11. Тире-венерология диспансерлары:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Төп персоналга караган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 100 дән артык |
| 2 | 35 тән 100 гә кадәр |
| 3 | 15 тән 35 кә кадәр |
| 4 | 15 кә кадәр |

6.3.12. Балалар терапия шифаханәләре, «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ш.С.Каратай исемендәге Республика тернәкләндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Койкалар саны |
|---|---|
| 1 | 350 дән артык |
| 2 | 300 дән 350 гә кадәр |
| 3 | 250 дән 300 гә кадәр |
| 4 | 200 дән 250 гә кадәр |
| 5 | 150 дән 200 гә кадәр |
| 6 | 100 дән 150 гә кадәр |
| 7 | 50 дән 100 гә кадәр |
| 8 | 50 гә кадәр |

6.3.13. Балалар йортлары:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | Койкалар саны |
|---|---|
| 1 | 250 дән артык |
| 2 | 200 дән 250 гә кадәр |
| 3 | 150 дән 200 гә кадәр |
| 4 | 100 дән 150 гә кадәр |
| 5 | 50 дән 100 гә кадәр |
| 6 | 50 гә кадәр |

6.4. Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары.

6.4.1. Тәүлек буе стационар ярдәм күрсәтүче, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы дәүләт оешмалары җитәкчеләренең (тире-венерология диспансерлары җитәкчеләреннән тыш) база һәм вазыйфаи эш хаклары, медицина ярдәме күрсәтү дәрәҗәсеннән һәм хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Медицина ярдәме күрсәтү дәрәҗәсе | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| III | 1 | 34 000 | 1,00 | 34 000 |
| III | 2 | 34 000 | 0,95 | 32 300 |
| III | 3 | 34 000 | 0,9 | 30 600 |
| III | 4 | 34 000 | 0,85 | 28 900 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| II | 1 | 28 500 | 1,0 | 28 500 |
| II | 2 | 28 500 | 0,95 | 27 075 |
| II | 3 | 28 500 | 0,9 | 25 650 |
| I | 1 | 25 700 | 1,0 | 25 700 |
| I | 2 | 25 700 | 0,95 | 24 415 |
| I | 3 | 25 700 | 0,9 | 23 130 |
| I | 4 | 25 700 | 0,85 | 21 845 |
| I | 5 | 25 700 | 0,8 | 20 560 |
| I | 6 | 25 700 | 0,75 | 19 275 |

6.4.2. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы дәүләт амбулатор-поликлиника оешмалары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 24 500 | 1,0 | 24 500 |
| 2 | 23 000 | 1,0 | 23 000 |
| 3 | 22 500 | 1,0 | 22 500 |
| 4 | 21 500 | 1,0 | 21 500 |
| 5 | 20 500 | 1,0 | 20 500 |
| 6 | 20 000 | 1,0 | 20 000 |

6.4.3. Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станцияләре җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 34 000 | 1,00 | 34 000 |
| 2 | 33 900 | 0,94 | 31 866 |
| 3 | 33 900 | 0,82 | 27 798 |

6.4.4. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм бу үзәкнең филиаллары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмасы исеме | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге | 1 | 26 600 | 1,00 | 26 600 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге филиаллары | 2 | 26 600 | 0,90 | 23 940 |

6.4.5. Медицина мәгълүмати-аналитика үзәкләре җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 21 500 | 1,00 | 21 500 |
| 2 | 21 500 | 0,95 | 20 425 |
| 3 | 21 500 | 0,90 | 19 350 |
| 4 | 21 500 | 0,85 | 18 275 |

6.4.6. Медицина профилактикасы үзәкләре җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 21 500 | 1,00 | 21 500 |
| 2 | 21 500 | 0,95 | 20 425 |
| 3 | 21 500 | 0,90 | 19 350 |
| 4 | 21 500 | 0,80 | 17 200 |

6.4.7. Табиб-физкультура диспансерлары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 21 500 | 1,00 | 21 500 |
| 2 | 21 500 | 0,95 | 20 425 |
| 3 | 21 500 | 0,85 | 18 275 |

6.4.8. Наркология диспансерлары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 25 200 | 1,00 | 25 200 |
| 2 | 25 200 | 0,95 | 23 940 |
| 3 | 25 200 | 0,90 | 22 680 |
| 4 | 25 200 | 0,80 | 20 160 |
| 5 | 25 200 | 0,75 | 18 900 |
| 6 | 25 200 | 0,70 | 17 640 |

Наркология диспансерлары эшчәнлеге үзенчәлекләрен, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятлелеген исәпкә алып, бу учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи эш хакларын билгеләгәндә вазыйфаи эш хакына карата 1,25 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Әлеге арттыру коэффициентын вазыйфаи эш хакына карата куллану компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи эш хакын барлыкка китерми.

6.4.9. Психиатрия диспансерлары (хастаханәләре, шифаханәләре) җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 31 500 | 1,00 | 31 500 |
| 2 | 31 500 | 0,95 | 29 925 |
| 3 | 31 500 | 0,90 | 28 350 |
| 4 | 31 500 | 0,80 | 25 200 |
| 5 | 31 500 | 0,75 | 23 625 |
| 6 | 31 500 | 0,70 | 22 050 |
| 7 | 31 500 | 0,65 | 20 475 |
| 8 | 31 500 | 0,60 | 18 900 |

Психиатрия диспансерлары (хастаханәләре, шифаханәләре) эшчәнлеге үзенчәлекләрен, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятлелеген исәпкә алып, бу учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи эш хакларын билгеләгәндә вазыйфаи эш хакына карата 1,25 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Әлеге арттыру коэффициентын вазыйфаи эш хакына карата куллану компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи эш хакын барлыкка китерми.

6.4.10. Туберкулезга каршы диспансерлар (хастаханәләр, шифаханәләр) җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 31 500 | 1,00 | 31 500 |
| 2 | 31 500 | 0,90 | 28 350 |
| 3 | 31 500 | 0,80 | 25 200 |
| 4 | 31 500 | 0,75 | 23 625 |
| 5 | 31 500 | 0,65 | 20 475 |

Туберкулезга каршы диспансерлар (хастаханәләр, шифаханәләр) эшчәнлеге үзенчәлекләрен, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятлелеген исәпкә алып, бу учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи эш хакларын билгеләгәндә вазыйфаи эш хакына карата 1,25 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Әлеге арттыру коэффициентын вазыйфаи эш хакына карата куллану компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи эш хакын барлыкка китерми.

6.4.11. Тире-венерология диспансерлары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 28 900 | 1,00 | 28 900 |
| 2 | 28 900 | 0,9 | 26 010 |
| 3 | 28 900 | 0,88 | 25 432 |
| 4 | 28 900 | 0,86 | 24 854 |

6.4.12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДка һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш һәм профилактика буенча республика үзәге җитәкчесенең база һәм вазыйфаи эш хакы түбәндәге күләмдәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмасы исеме | База эш хакы, сум | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДка һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш һәм профилактика буенча республика үзәге | 26 000 | 26 000 |

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДка һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш һәм профилактика буенча республика үзәге эшчәнлеге үзенчәлекләрен, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятлелеген исәпкә алып, бу учреждение җитәкчесенең вазыйфаи эш хакын билгеләгәндә вазыйфаи эш хакына карата 1,8 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Әлеге арттыру коэффициентын вазыйфаи эш хакына карата куллану компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи эш хакын барлыкка китерми.

6.4.13. Балалар терапия шифаханәләре, «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ш.С.Каратай исемендәге Республика тернәкләндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 25 000 | 1,00 | 25 000 |
| 2 | 25 000 | 0,95 | 23 750 |
| 3 | 25 000 | 0,90 | 22 500 |
| 4 | 25 000 | 0,85 | 21 250 |
| 5 | 25 000 | 0,80 | 20 000 |
| 6 | 25 000 | 0,75 | 18 750 |
| 7 | 25 000 | 0,70 | 17 500 |
| 8 | 25 000 | 0,65 | 16 250 |

6.4.14. Балалар йортлары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары, хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База эш хакы, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе | Вазыйфаи эш хакы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 28 000 | 1,00 | 28 000 |
| 2 | 28 000 | 0,95 | 26 600 |
| 3 | 28 000 | 0,90 | 25 200 |
| 4 | 28 000 | 0,85 | 23 800 |
| 5 | 28 000 | 0,80 | 22 400 |
| 6 | 28 000 | 0,65 | 18 200 |

6.4.15. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган оешмалар җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи эш хаклары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы дәүләт оешмалары исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 33 800 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Резерв» республика медицина мобилизация резервлары үзәге» дәүләт казна сәламәтлек саклау учреждениесе | 20 500 |
| «Республика медицина китапханә-мәгълүмат үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | 23 800 |
| «Тернәкләндерү» дәүләт автоном учреждениесе | 13 650 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | 36 600 |

6.5. Дәүләт оешмасы җитәкчесе урынбасарларының (шул исәптән директорының), дәүләт оешмасы баш бухгалтерының һәм баш шәфкать туташының (баш акушерының, баш фельдшерының) вазыйфаи эш хаклары бу дәүләт оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи эш хакыннан 10 – 30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

Кайбер медицина оешмалары эшчәнлеге үзенчәлекләрен, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятлелеген исәпкә алып, бу учреждениеләр җитәкчеләре урынбасарларының (шул исәптән директорының), баш бухгалтерының һәм баш шәфкать туташының (баш акушерының, баш фельдшерының) вазыйфаи эш хакларын билгеләгәндә вазыйфаи эш хакына карата түбәндәге арттыру коэффициентлары кулланыла:

наркология диспансерлары, туберкулезга каршы диспансерлар (хастаханәләр, шифаханәләр), психиатрия диспансерлары (хастаханәләре, шифаханәләре) – 1,25;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДка һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш һәм профилактика буенча республика үзәге – 1,8.

Әлеге арттыру коэффициентын вазыйфаи эш хакына карата куллану компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи эш хакын барлыкка китерми.

6.6. Учреждение җитәкчесе, аның урынбасарлары (шул исәптән директоры), медицина оешмасының баш бухгалтеры һәм баш шәфкать туташы (баш акушеры, баш фельдшеры) өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

6.7. Дәүләт оешмасы җитәкчесе дәүләт оешмасы җитәкчесе урынбасарларына (шул исәптән директорына), баш бухгалтерына һәм баш шәфкать туташына (баш акушерына, баш фельдшерына), аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлегенең нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен вазыйфаи эш хакы күләмендә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләргә мөмкин. Җитәкче урынбасарларына (шул исәптән директорга), баш бухгалтерга һәм баш шәфкать туташына (баш акушерга, баш фельдшерга) стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер ел өчен эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.8. Дәүләт оешмасын гамәлгә куючы дәүләт оешмасы җитәкчесенә, дәүләт оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән дәүләт оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен вазыйфаи эш хакы күләмендә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләргә мөмкин. Дәүләт оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел өчен эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.9. Ведомство буйсынуындагы дәүләт оешмалары җитәкчеләрен стимуллаштыру турындагы карарлар гамәлгә куючының норматив хокук акты белән рәсмиләштерелә.

6.10. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү турындагы нигезләмәләр җитәкче, җитәкче урынбасарлары (шул исәптән директор), баш бухгалтер һәм баш шәфкать туташы (баш акушер, баш фельдшер) белән гамәлгә куючы арасында төзелә торган хезмәт шартнамәсенә теркәлә торган өстәмә килешүдә чагылыш таба. Хезмәт шартнамәсенә өстәмә килешү бер елга кадәр дип төзелә. Календарь ел беткәннән соң, хезмәт шартнамәсенә өстәмә килешү дәүләт оешмасы җитәкчесен, аның урынбасарларын (шул исәптән директорын), баш бухгалтерын һәм баш шәфкать туташын (баш акушерын, баш фельдшерын) стимуллаштыруның гомуми фонды күләмнәрен, шулай ук дәүләт оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары исемлеген һәм мәгънәләрен үзгәртү өлешендә яңадан каралырга мөмкин.

6.11. Дәүләт оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына штатта торган оешмаларда, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрне исәпкә алып, тиешле белгечлек табибының вазыйфаи эш хакыннан 25 процент күләмендә акча түләп, төп вазыйфасы буенча эш вакыты чикләрендә табиб белгечлеге буенча эш алып бару рөхсәт ителә.»;

7 бүлекнең 7.2 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә теркәлгән 12 нче кушымтада:

49 нчы өстәмәләр коды буенча 5 нче графада «40» саннарын «30» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең гомумтармак эшче профессияләре һәм гомумтармак җитәкчеләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

3 нче бүлекнең 3.4 нче пунктындагы сигезенче абзацта «3 мең сум тәшкил итә» сүзләрен «5 мең сум тәшкил итә» сүзләренә алыштырырга;

Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада таблица башының 1 нче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмәләр коды»;

49 нчы өстәмәләр коды буенча 5 нче графада «40» саннарын «30» саннарына алыштырырга.

2. Бу карарның гамәле (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган һәм 2018 елның 1 февраленнән үз көченә керә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә теркәлгән 12 нче кушымтага һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең гомумтармак эшче профессияләре һәм гомумтармак җитәкчеләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтага кертелә торган үзгәрешләрдән тыш) 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин